КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 август г.Казань № 747

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 12 апрель, 234 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 декабрь, 1087 нче; 2011 ел, 29 июнь, 526 нчы; 2011 ел, 29 июль, 609 нчы; 2011 ел, 7 июль, 747 нче; 2012 ел, 27 апрель, 330 нчы; 2012 ел, 30 июнь, 567 нче; 2012 ел, 30 июль, 645 нче; 2012 ел, 27 октябрь, 908 нче; 2013 ел, 19 март, 186 нчы; 2013 ел, 29 апрель, 296 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1111 нче; 2014 ел, 20 май, 332 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1039 нчы; 2015 ел, 10 март, 143 нче; 2016 ел, 26 февраль, 118 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 996 нчы; 2017 ел, 18 май, 291 нче; 2017 ел, 15 декабрь, 999 нчы; 2018 ел, 23 апрель, 278 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 17 декабрь, 1156 нчы; 2019 ел, 29 гыйнвар, 52 нче; 2019 ел, 23 май, 433 нче; 2019 ел, 13 июнь, 492 нче; 2019 ел, 11 сентябрь, 815 нче; 2019 ел, 21 сентябрь, 866 нчы, 2019 ел, 30 сентябрь, 883 нче, 2020 ел, 24 февраль, 132 нче, 2020 ел, 17 апрель, 300 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәнең 3 бүлеген редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Дәүләт комитеты функцияләре

3.1. Дәүләт комитеты түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җаваплы:

бәяләрне (тарифларны) җайга салу (01.08*);

дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (01.08.01*);

3.2. Дәүләт комитеты түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

3.2.1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.02*);

3.2.2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функцияләрен гамәлгә ашырганда (02.03*);

3.2.3. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

цифрлаштыру белән идарә итү (01.15*);

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән тыш) (01.15.02*;

3.2.4. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән мәдәният өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу функциясен гамәлгә ашырганда (шул исәптән сәнгать, кинематография, тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм куллану), төрле диннәрнең дини берләшмәләре арасында үзара аңлашуны һәм сабырлыкны ныгытуга ярдәм итү (04.03*);

3.2.5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән сәламәтлек саклау белән идарә итү функцияләрен тормышка ашырганда (04.02*);

3.2.6. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы белән табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.06*);

3.2.7. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү һәм кулланучыларга сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү белән идарә итү (04.01*);

калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру (01.06.09*);

3.2.8. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы эшләре, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә функцияләрен гамәлгә ашырганда (02.01*);

3.2.9. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән транспорт һәм юл комплекслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (03.03*);

---

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторы нигезендә кодны билгеләү.

3.2.10. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.07*);

3.2.11. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән

түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

хезмәт белән идарә итү (01.13*);

социаль яклау белән идарә итү (04.06*).

3.2.12. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән социаль-икътисадый программалаштыру функциясен гамәлгә ашырганда (01.01*);

3.2.13. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән энергияне һәм ресурсларны саклау белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.14*);

3.2.14. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.17*);

3.2.15. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе белән үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге функцияләрен гамәлгә ашырганда (03.02.05*).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин